| ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ВЕТЕРИНАРИИ КАБИНЕТА МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.02.2022 Казан шәһәре № 14-од

Хайваннар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе (аларга җаваплар тикшерүдә тотылучы зат тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлеге) үрнәген раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тоту һәм муниципаль тикшерүдә тоту турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ санлы федераль законның 53 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерү кәгазьләре үрнәкләре проектларын эшләү, аларның эчтәлегенә, алар турында иҗтимагый фикер алышуга, тикшерү кәгазьләре үрнәкләрен раслау, куллану, актуальләштерүгә карата таләпләр, шулай ук тикшерү кәгазьләрен зарури куллану очракларын раслау турында» 2021 елның 27 октябрендәге 1844 санлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Хайваннар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе (аларга җаваплар тикшерүдә тотылучы зат тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлеге) үрнәген (кушымтада бирелә) расларга.

2. Әлеге боерык 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе урынбасары И.Н.Ногомановка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты
Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе А.Г. Хисаметдинов

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
Баш ветеринария идарәсенең
2022 елның 17 февралендәге 14-од
санлы боерыгы белән расланды

Үрнәк

QR-код

**Хайваннар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе (аларга җаваплар тикшерүдә тотылучы зат тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлеге)**

1. Тикшерү кәгазе (аларга җаваплар тикшерүдә тотылучы зат тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлеге) хайваннар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе тарафыннан кулланыла.

2. Федераль дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тоту, төбәк дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тоту, муниципаль тикшерүдә тоту төрләренең бердәм реестрына кертелгән тикшерүдә тоту төренең атамасы:

______________________________________________________________

3. Тикшерү (күзәтчелек) органының атамасы һәм тикшерү кәгазе үрнәген раслау турында норматив хокукый акт белешмәләре:

______________________________________________________________________________

4. Тикшерүдә тоту (күзәтчелек) чарасының төре: __________________________________________________

5. Тикшерү битен тутыру көне: ________________________________________________________________

6. Үзенә карата тикшерүдә тоту (күзәтчелек) чарасы үткәрелә торган тикшерүендә (күзәтчелегендә) тоту объекты:

______________________________________________________________________________

тикшерүдә тотылучы затлар булып торган гражданинның яисә шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта), салым түләүче буларак тәңгәллек саны һәм (яисә) шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәү саны, гражданинның яки шәхси эшкуарның теркәлү адресы, юридик затның атамасы, аның салым түләүче буларак тәңгәллек саны һәм (яисә) төп дәүләт теркәү саны, юридик затның (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерым корылыш бүлекчәләренең) адресы

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

7. Тикшерү кәгазен тутырып тикшерүдә тоту (күзәтчелек) чарасын үткәрү урыны (урыннары):

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

8. Тикшерүдә тоту (күзәтчелек) чарасын үткәрү турында вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе күрсәтмәсе (боерыгы) белешмәләре:

______________________________________________________________________________

9. Тикшерүдә тоту (күзәтчелек) чарасының исәпкә алу саны (тикшерү саны һәм аны «Тикшерүдә тоту (күзәтчелек) чараларының бердәм реестры» ФДМС беркетү көне):

______________________________________________________________________________

10. Тикшерүдә тоту төре турындагы нигезләмә, вазыйфаи регламент яисә вазыйфаи күрсәтмә нигезендә тикшерүдә тоту төре буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, шул исәптән тикшерүдә тоту (күзәтчелек) чараларын уздыру аның вазыйфаи бурычларына карый торган, тикшерүдә тоту (күзәтчелек) чарасын уздырган һәм тикшерү кәгазен тутырган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе вазыйфаи затының вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары:

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

11. Аларга бирелгән җаваплар тикшерүдә тотылучы зат тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында таныклый торган зарури таләпләрнең эчтәлеген чагылдырган тикшерү сораулары исемлеге:

| № т/с | Тикшерү сораулары исемлеге | Зарури таләпләрне билгели торган норматив хокукый актларның, аларның бүленеш берәмлекләрен күрсәтеп, белешмәләре | Сорауларга җаваплар | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Әйе (билгеләнгән зарури таләпкә туры килә) | Юк (билгеләнгән зарури таләпкә туры килми) | Кулла-нып бул-мый | |
| I. Хайваннар тотуга карата гомуми таләпләр. | | | | | | |
| 1. | Малларны тиешенчә карау тәэмин ителгәнме? | «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ санлы федераль законның (алга таба – Закон) 9 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты | | | | |
| 2. | Закон, ветеринария өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга сала торган башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары таләпләре нигезендә терлекләргә ветеринария ярдәмен үз вакытында күрсәтү һәм зарури профилактик ветеринария чараларын үз вакытында гамәлгә ашыру тәэмин ителгәнме? | Законның 9 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты | | | | |
| 3. | Хайваннарда теләнмәгән нәсел дәвамчанлыгын булдырмый калу буенча чаралар күреләме? | Законның 9 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты | | | | |
| 4. | Хайваннар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге органнарының вазыйфаи затлары таләбе буенча аларны тоту урыны буенча хайваннар күрсәтеләме? | Законның 9 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктчасы | | | | |
| 5. | Биологик калдыклар белән эш итү | Законның 9 статьясындагы | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыламы? | 1 өлешенең 5 пункты | | | | |
| 6. | Хайванга милек хокукыннан баш тарткан очракта яки алга таба аны карап тоту мөмкин булмаган очракта, хайванның хуҗасы аны мондый хайванны тоту шартларын тәэмин итә ала торган яңа хуҗасына яки приютка тапшырамы? | Законның 9 статьясындагы 2 өлеше | | | | |
| II. Хуҗасыз хайваннар белән эш итү буенча эшчәнлекне тормышка ашырганда чаралар оештыру. | | | | | | |
| 7. | Хуҗасыз хайваннарны тотып алу, шул исәптән аларны транспортлау һәм хайваннар өчен приютларга кичекмәстән тапшыру гамәлгә ашырыламы? | Законның 18 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты | | | | |
| 8. | Югалган хайваннарны аларның хуҗаларына кире кайтару, шулай ук хайваннар приютларына китерелгән хуҗасыз хайваннар өчен яңа хуҗалар эзләү гамәлгә ашырыламы? | Законның 18 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты | | | | |
| 9. | Нигезсез рәвештә агрессивлык күрсәтми торган хуҗасыз хайваннар, чаралар (стерильләштерү, вакцинация, дәвалау) уздырылганнан соң элеккеге яшәү урыннарына кире кайтарыламы? | Законның 18 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты | | | | |
| 10. | Мондый хайваннарны яңа хуҗаларына тапшыру мизгеленә кадәр яки мондый хайваннар табигый рәвештә үлгәнчегә кадәр, хайваннар өчен приютларда хуҗалары булмаган, элеккеге яшәү урыннарына кайтарыла алмый торган хайваннар урнаштырыламы һәм тотыламы? | Законның 18 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты | | | | |
| 11. | Хуҗалары булмаган, салдырылмый яки юылмый торган тамгалары булган стерильләштерелгән хайваннар тотып алынамы, башка хайваннарга яки кешегә | Законның 18 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | карата нигезсез рәвештә агрессивлык күрсәтә торган, хуҗасыз хайваннардан тыш? | | | | | |
| 12. | Муенчагында яки башка предметларда хуҗалары турында белешмәләре булган, тотып алынган хайваннар хуҗаларына тапшырыламы? | Законның 18 статьясындагы 2 өлешенең 2 пункты | | | | |
| 13. | Хайваннарның имгәнүенә, җәрәхәт алуына яки үлеменә китерә торган матдәләр, дару чаралары, ысуллар, техник җайланмалар кулланыламы? | Законның 18 статьясындагы 2 өлешенең 3 пункты | | | | |
| 14. | Хуҗасыз хайваннарны тотып алу барышы видеога яздырыламы һәм Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы таләбе буенча әлеге видеоязманың күчермәсе түләүсез биреләме? | Законның 18 статьясындагы 2 өлешенең 5 пункты | | | | |
| 15. | Хуҗасыз хайваннарны аулаучы шәхси эшкуарлар (юридик затлар) башкарылган эшләр күләме турындагы белешмәләрне Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына тапшыралармы? | Законның 18 статьясындагы 2 өлешенең 6 пункты | | | | |
| 16. | Хуҗасыз хайваннарны, хуҗасыз хайваннар иҗтимагый куркыныч тудырган очраклардан тыш, балалар катнашында тотып алу гамәлгә ашырыламы? | Законның 18 статьясындагы 3 өлеше | | | | |
| 17. | Тотылган хуҗасыз хайваннар хайваннар өчен приютлар булып тормаган, хайваннарны вакытлыча тоту урыннарында һәм пунктларында тотыламы? | Законның 18 статьясындагы 5 өлеше | | | | |
| 18. | Хуҗасыз хайваннарны кире кайтару эше видеога төшереләме һәм Россия Федерациясе субъекты башкарма | Законның 18 статьясындагы 6 өлеше | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | хакимиятенең вәкаләтле органы таләбе буенча әлеге видеоязманың күчермәсе түләүсез бирeләме? | | | | | |
| 19. | Махсуслаштырылган оешма, хуҗасыз хайваннарны тотып алу буенча планлы чаралар үткәрүгә өч көн кала, халыкка массакүләм мәгълүмат чаралары, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, хуҗасыз хайваннарны тотып алу урыннары һәм вакытлары турында мәгълүмат җиткерүне гамәлгә ашырамы? | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 30 декабрендәге 1275 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең (алга таба – Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибе) 2.4 пункты | | | | |
| 20. | Хуҗасыз хайваннарны тотып алучы бригада кимендә ике кешедән торамы, алар составына, шул исәптән, ветеринария өлкәсе белгече кертелгәнме? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.8 пункты | | | | |
| 21. | Махсуслаштырылган оешманың хуҗасыз хайваннарны тотып алу һәм асрап тотуны уздыручы хезмәткәрләрен котыру авыруына каршы вакцинацияләү гамәлгә ашырыламы? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.9 пункты | | | | |
| 22. | Хуҗасыз хайваннарны тотып алу махсуслаштырылган оешма хезмәткәрләре – психоневрология һәм наркология диспансерларында исәптә тормаган балигъ булмаган гражданнар тарафыннан гамәлгә ашырыламы? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.9 пункты | | | | |
| 23. | Хуҗасыз хайваннарны тотып алуны уздырганда махсуслаштырган оешма хезмәткәрләрендә Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенә 1 нче кушымта нигезендәге | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.10 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | үрнәк буенча махсуслаштырылган оешма тарафыннан бирелгән махсуслаштырылган оешма хезмәткәренең хезмәт таныклыгы үзе беләнме? | | | | | |
| 24. | Хуҗасыз хайваннарны тотып алучы бригадалар, «оча торган» шприцлы яки «оча торган» сөңгеле пневможайланманы да кертеп, тотып алу чаралары, махсус кием-салым, махсус аяк киеме һәм башка төрле шәхси саклык чаралары белән тәэмин ителгәнме? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.11 пункты | | | | |
| 25. | Костюмга һәм курткага махсус оешманың аңлаешлы укыла торган исеме һәм телефон номеры теркәлгән язу төшерелгәнме? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.11 пункты | | | | |
| 26. | Махсус кием даими зарарсызландыруга һәм юдыруга дучар ителәме? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.11 пункты | | | | |
| 27. | Хуҗасыз хайваннарны тотып алу уздырылган шул ук көнне Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенә карата 2 нче кушымтадагы үрнәк буенча, тотып алынган хуҗасыз хайваннарның хакыйкый санын күрсәтеп, тотып алу турында акт төзеләме? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.16 пункты | | | | |
| 28. | Хуҗасыз хайваннарны тотып алуны уздырган шул ук көнне махсуслаштырылган оешма хезмәткәрләре тарафыннан  Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенә карата 2 нче кушымтадагы үрнәк буенча, тотып алынган хуҗасых хайваннарның | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.16 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | хакыйкый санын күрсәтеп, тотып алу турында акт төзеләме? | | | | | |
| 29. | Тотып алган вакытта һәлак булган хайваннар, үлем сәбәбен тотып алу актында күрсәтеп, исәпкә алынамы? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.17 пункты | | | | |
| 30. | Тотып алганда үлгән хайваннар үлем сәбәбен билгеләү һәм хуҗасыз хайваннар санын исәпкә алу өчен приютка китереләме? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.17 пункты | | | | |
| 31. | Тотып алынган хуҗасыз хайваннарны приютка транспорт белән китерү кешеләрнең һәм хайваннарның җәрәхәт алу ихтималын юкка чыгара торган, хайваннарны йөртү өчен махсус җиһазландырылган машина (алга таба – махсус машина) белән гамәлгә ашырыламы? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.18 пункты | | | | |
| 32. | Махсус машина техник яктан төзек хәлдәме? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.19 пункты | | | | |
| 33. | Тотып алынган хуҗасыз хайваннарны транспорт белән күчерү өчен махсус машинада махсус оешманың аңлаешлы укыла торган атамасы һәм приют адресы белән язулар бармы? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.20 пункты | | | | |
| 34. | Тотып алынган хуҗасыз хайваннарны транспорт белән күчерү өчен махсус машинада табигый җилләтү бармы? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.20 пункты | | | | |
| 35. | Тотып алынган хуҗасыз хайваннарны транспорт белән күчерү өчен махсус машинада хуҗасыз хайваннар өчен эчә торган су запасы бармы? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.20 пункты | | | | |
| 36. | Тотып алынган хуҗасыз хайваннарны | Хуҗасыз хайваннар белән | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | транспорт белән күчерү өчен махсус машинада тотып алу барышында зыян күргән кешеләргә һәм хайваннарга беренче дәвалау ярдәмен һәм (яки) ветеринария ярдәмен күрсәтү өчен ярашлылык сертификатына ия булган дәвалау препаратларын һәм ветеринариядә куллану өчен препаратларны үз эченә алган медикаментлар җыелмасы бармы? | эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.20 пункты | | | | |
| 37. | Тотып алынган хуҗасыз хайваннарны транспорт белән күчерү өчен махсус машинада хуҗасыз хайваннарны транспорт белән күчерү өчен йөртүче кабинасыннан аерым, изоляцияләнгән, төрле төр, токым, җенес, үлчәм, яшьтәге хуҗасыз хайваннар өчен аерым читлекләр (бүлемтекләр) белән җиһазландырылган ябык бүлемтек бармы? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.20 пункты | | | | |
| 38. | Тотып алынган хуҗасыз хайваннарны транспорт белән күчерү өчен махсус машинада кирәк булган очракта куллану өчен муенчаклар, баулар, борынлыклар бармы? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.20 пункты | | | | |
| 39. | Хуҗасыз хайваннарны төягәндә, транспорт белән күчергәндә һәм бушатканда кешеләрнең һәм хайваннарның имгәнүен булдырмый кала торган җайланмалар һәм алымнар куллану тәэмин ителәме? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.21 пункты | | | | |
| 40. | Тотып алынган хуҗасыз этләрне транспортлау өчен махсус автомобиль көндезге ут керерлек итеп җиһазландырылганмы? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.24 пункты | | | | |
| 41. | Автотранспорт чарасында алып барыла | Хуҗасыз хайваннар белән | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | торган хуҗасыз хайваннарның мөмкин булган иң күп баш саны 10 баштан артмыймы? | эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.25 пункты | | | | |
| 42. | Хуҗасыз хайваннарны транспорт белән алып баруның чик вакыты 5 сәгатьтән артып китмиме? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.26 пункты | | | | |
| 43. | Хуҗасыз хайваннарны тотып алынган урыннан транспорт белән алып бару аралыгы 300 км артып китмиме? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.26 пункты | | | | |
| 44. | Хуҗасыз хайваннарны транспорт белән күчергәндә махсус машинада төрле төрдәге аерым читлекләр (бүлемтекләр) кулланыламы? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.27 пункты | | | | |
| 45. | Транспорт чарасында бер төрле һәм үлчәмле, бер-берсенә карата агрессия күрсәтми торган берничә хайванны бер читлектә (бүлемтектә) урнаштыру рөхсәт ителәме? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.28 пункты | | | | |
| 46. | Транспорт чарасында ана хайванны балалары белән бер читлектә (бүлемтектә) урнаштыру рөхсәт ителәме? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.28 пункты | | | | |
| 47. | Транспорт чарасында бер төргә караган хайван балаларын бер читлектә (бүлемтектә) урнаштыру рөхсәт ителәме? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.28 пункты | | | | |
| 48. | Хуҗасыз хайваннарны транспорт белән күчергәндә аларны урнаштыру өчен читлек (бүлемтек) үлчәме хайванның табигый торыш алу, шулай ук яту һәм тору мөмкинлеген бирәме? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.29 пункты | | | | |
| 49. | Транспорт белән күчергәндә берничә хайванны бер читлектә (бүлемтектә) урнаштырган вакытта, бөтен хайваннарга | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.29 | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | берьюлы, бер-берсенә зыян китермчә тору һәм яту мөмкинлеге тудырылганмы? | пункты | | | | |
| 50. | Тотып алынган хуҗасыз хайваннарны хайван мәетләре белән бергә алып бару рөхсәт ителәме? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.29 пункты | | | | |
| 51. | Тотып алынган хуҗасыз хайваннарны транспорт белән күчерү өчен махсус машина хайваннарны һава шартларына каршы иминлек һәм яклау тәэмин итәме? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.30 пункты | | | | |
| 52. | Хуҗасыз хайваннарны тотып алу һәм транспорт белән күчерү эшләре тәмамланганнан соң махсус машинаның кузовы – көн саен, ә җайланмалар һәм күчмә читлекләр (бүлемтекләр) пычрану дәрәҗәсенә карап йогышсызландыру буенча эшкәртеләме? | Хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 2.31 пункты | | | | |
| III. Хайваннар өчен приютларга карата таләпләр. | | | | | | |
| 53. | Хайваннар өчен приют моның өчен махсус билгеләнгән бинада, төзелмәдә, корылмада урнаштырылганмы? | Законның 16 статьясындагы 2 өлеше | | | | |
| 54. | Хайваннар өчен приютларга килгән хуҗасыз хайваннарга һәм хуҗалары милек хокукыннан баш тарткан хайваннарга карата карау уздырыламы һәм ун көн дәвамында зарури карантин чаралары гамәлгә ашырыламы, мондый хайваннарга котыру һәм кеше һәм хайваннар өчен куркыныч булган башка авырулардан вакцинация уздырыламы? | Законның 16 статьясындагы 7 өлешенең 1 пункты | | | | |
| 55. | Хуҗасыз хайваннар һәм хуҗалары милек хокукыннан баш тарткан хайваннар өчен приютларга китерелгән хайваннарны исәпкә алу, салдырылмый һәм юылмый торган тамгалар белән маркалау гамәлгә ашырыламы? | Законның 16 статьясындагы 7 өлешенең 2 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 56. | Хайваннар өчен приютларга китерелгән хуҗасыз хайваннарга карата стерильләштерү гамәлгә ашырыламы? | Законның 16 статьясындагы 7 өлешенең 3 пункты | | | | |
| 57. | Хайваннар өчен приютларга китерелгән хуҗаыз хайваннар һәм хуҗалары милек хокукыннан баш тарткан хайваннар мондый хайваннар табигый рәвештә үлгәнчегә кадәр яисә мондый хайваннарны аларның элек яшәгән урыннарына кайтарганчы яки мондый хайваннарны яңа хуҗаларына тапшырганчыга кадәр карап тотылалармы? | Законның 16 статьясындагы 7 өлешенең 4 пункты | | | | |
| 58. | Муенчакларында яки башка предметларда хуҗалары турында белешмәләр булган хайваннар хуҗаларына кире кайтарыламы? | Законның 16 статьясындагы 7 өлешенең 5 пункты | | | | |
| 59. | Хайванны югалткан хуҗага яки мондый хайванның хуҗасы тарафыннан вәкаләт бирелгән затка хайванны хайваннар өчен приютларда тотыла торган хуҗасыз хайваннарны карау юлы белән эзләү мөмкинлеге тәэмин ителәме? | Законның 16 статьясындагы 7 өлешенең 6 пункты | | | | |
| 60. | Хайваннар өчен приютларда булган хуҗасыз хайваннар һәм хуҗалары милек хокукыннан баш тарткан хайваннар турындагы белешмәләр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырыламы? | Законның 16 статьясындагы 7 өлешенең 7 пункты | | | | |
| 61. | Хайваннарның хайваннар өчен приютларга килүе һәм хайваннар өчен приютлардан хайваннарның китүе турында документ белән расланган исәп алып барыламы? | Законның 16 статьясындагы 7 өлешенең 8 пункты | | | | |
| 62. | Хуҗасыз хайваннарны һәм хуҗалары милек хокукыннан баш тарткан | Законның 16 статьясындагы 8 өлеше | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | хайваннарны мондый хайваннарны лаборатор хайваннар рәвешендә файдалану өчен физик затларга һәм юридик затларга тапшыру гамәлгә ашырыламы? | | | | | |
| 63. | Хайваннар өчен приют хезмәткәрләре тарафыннан хайваннар өчен приютка китерелгән һәр хуҗасыз хайван һәм хуҗасы милек хокукыннан баш тарткан хайван турындагы белешмәләр (фотосы, кыскача тасвирлама, ачыклау көне һәм урыны һәм башка төрле өстәмә мәгълүматлар) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле хайван хайваннар өчен приютка килгән көннән башлап өч көннән дә соңга калмыйча урнаштырыламы? | Законның 16 статьясындагы 9 өлеше | | | | |
| 64 | Хайванның ветеринария өлкәсе белгече тарафыннан төгәл билгеләнгән катлаулы, дәвалап булмый торган авыруы яки каты җәрәхәтнең дәвалап булмый торган, хайванның исәнлеге белән ярашмый торган нәтиҗәләре булган очракта, яшәргә сәләтле булмаган хайваннарны кичереп булмый торган физик җәзаланудан туктату зарурлыгы булган очраклардан тыш, хайваннар өчен приютларда тотыла торган хайваннар үтереләме һәм үтерү ветеринария өлкәсе белгече тарафыннан тиз һәм авыртусыз үлем булуын ышандыра торган шәфкатьле алымнар белән гамәлгә ашырыламы? | Законның 16 статьясындагы 11 өлеше | | | | |
| 65. | Хайваннар өчен приютларның хуҗалары һәм алар вәкаләт биргән затлар тарафыннан, бүлмәләргә санитар эшкәртү | Законның 16 статьясындагы 12 өлешенең 1 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | яки йогышсызландыру уздырылган көннәрдән тыш, хайваннар өчен приютларда билгеләнгән вакытта гражданнар тарафыннан хайваннар өчен приютларга килү мөмкинлеге тәэмин ителәме? | | | | | |
| 66. | Хайваннар өчен приютларның хуҗалары һәм алар вәкаләт биргән затлар тарафыннан, бүлмәләргә санитар эшкәртү яки йогышсызландыру уздырылган көннәрдән тыш, хайваннар өчен приютларда билгеләнгән эш режимында билгеләнгән сәгатьләрдә ирекле затлар (волонтерлар) тарафыннан хайваннар өчен приютларга килү мөмкинлеге тәэмин ителәме? | Законның 16 статьясындагы 12 өлешенең 2 пункты | | | | |
| 67. | Хайваннар өчен приютны иҗтимагый, административ яки җитештерү биналарының изоляцияләнгән өлешләрендә, шулай ук фатирларда урнаштыру рөхсәт ителәме? | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 28 февралендәге 150 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар өчен приютларның эшчәнлеген оештыру тәртибе һәм аларда хайваннарны тоту нормаларының (алга таба – Хайваннар өчен приютлар эшчәнлеген оештыру тәртибе) 2.2 пункты | | | | |
| 68. | Хайваннар өчен приют торак төзелешеннән кимендә 150 метрлы аралыкны саклап урнаштырылганмы? | Хайваннар өчен приютлар эшчәнлеген оештыру тәртибенең 2.3 пункты | | | | |
| 69. | Хайваннар өчен приют территориясе кимендә 2 метр биеклектә, цоколе булган, | Хайваннар өчен приютлар эшчәнлеген оештыру | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | җиргә кимендә 0,4 метр күмелгән тоташ койма белән әйләндереп алынганмы? | тәртибенең 2.4 пункты | | | | |
| 70. | Хайваннар өчен приют коймасы периметры буенча яшел үсентеләр урнаштырыламы? | Хайваннар өчен приютлар эшчәнлеген оештыру тәртибенең 2.4 пункты | | | | |
| 71. | Хайваннар өчен приют территориясе түбәндәге зоналарга бүленгәнме:<br>хайваннарны даими тоту өчен биналар һәм хайваннарны йөртү өчен мәйданчыкларны үз эченә алган җитештерү зонасы?<br>административ-хуҗалык зонасы, административ-хуҗалык хезмәтләре биналарын һәм корылмаларын, ярдәмче бүлмәләрне, терлек азыгы кухнясын (хайваннарны хайваннар өчен әзер булмаган ризык белән тукландырган очракта) һәм терлекләр өчен азык саклау складын үз эченә ала?<br>хайваннарны вакытлы тоту зонасы, манеж-кабул итү бүлмәсен, карантин бүлмәсен, изоляторны, ветеринария пунктын, шулай ук стационар шартларда хайваннарны дәвалау өчен билгеләнгән бүлмәне үз эченә ала?<br>биологик калдыкларны саклау? | Хайваннар өчен приютлар эшчәнлеген оештыру тәртибенең 2.5 пункты | | | | |
| 72. | Хайваннар өчен приют территориясенә транспорт белән керү (чыгу) йогышсызландыру киртәсе аша гамәлгә ашырыламы? | Хайваннар өчен приютлар эшчәнлеген оештыру тәртибенең 2.5 пункты | | | | |
| 73. | Приют территориясенә, шул исәптән административ-хуҗалык зонасына (хайваннарны даими тоту өчен бүлмәләргә) һәм хайваннарны вакытлыча тоту зонасына (манеж-кабул итү бүлмәсенә, карантин бүлмәсенә, | Хайваннар өчен приютлар эшчәнлеген оештыру тәртибенең 2.5 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | изоляторга, ветеринария пунктына, стационар шартларында хайваннарны дәвалау өчен билгеләнгән бүлмәгә) керү урыны йогышсызландыру эретмәләре белән туендырылган йогышсызландыру келәмнәре белән җиһазландырылганмы? | | | | | |
